### 1267. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 46088-7 номерлы федераль закон проекты турында (этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция сату кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны арттыру хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 46088-7 номерлы федераль закон проектын (этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция сату кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны арттыру хакында) хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 16 феврале
№ 1649-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1268. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 25.7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 25.7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Соб-

раниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 16 феврале
№ 1650-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1269. Р.Н. Абзаловны Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәтен белдерүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында озак еллар фидакарь хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының эшләр идарәчесе урынбасары Абзалов Рифкать Нургали улын Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәтен белдерүгә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 23 гыйнвары
№ 1595-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1270. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы гамәлгә куючыларының берсе булган «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләренең эшчәнлеге турында

Газеталарның баш мөхәррирләре (М.М. Сәфәров, А.Н. Латышев) докладларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзалары һәм чакырылганнар чыгышларын тыңлап һәм бу хакта фикер алышып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә куючылар булган «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре, гомумән алганда, республика халкына мәгълүмат бирү буенча үзләренә йөкләнгән бурычларны үтиләр дип билгеләп үтә.

«Ватаным Татарстан» газетасының тарихы 1918 елда оештырылган «Эш» (алга таба төрле елларда ул – «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан») газетасыннан башлана. «Республика Татарстан» газетасының башы 1917 елда чыга башлаган «Рабочий» газетасына барып тоташа (алга таба – «Знамя революции», «Знамя труда», «Известия» «Известия ТатЦИКа», «Красная Татария», «Советская Татария» газеталары). 2017 – 2018 елларда республиканың әлеге матбугат басмалары 100 еллык юбилейларын билгеләп үтәчәк.

«Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре дәүләт бюджет учреждениеләре булып санала. Гамәлгә куючылар һәм газеталар редакцияләре арасындагы мөнәсәбәт «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, газеталарның уставлары, шулай ук тиешле шартнамәләр нигезендә төзелә. Гамәлгә куючылар тарафыннан ел саен редакцияләргә дәүләт заданиеләре раслана, баш мөхәррирләр белән вакытлы хезмәт шартнамәләре төзелә. Гамәлгә куючылар мәнфәгатьләрен килештерү һәм гамәлгә куючылар компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен гамәлгә куючылар советлары төзелде, аларга һәр гамәлгә куючыдан дүртәр вәкил кертелде.

Татарстан Республикасы халкы мәнфәгатьләренә кагылышлы мөһим иҗтимагый белешмәләре булган хәбәрләр һәм матери-

аллар бастырып чыгару юлы белән гражданнарның мәгълүмат алуга конституциячел хокукларын тәэмин итү «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре эшчәнлегенең төп максаты булып тора.

«Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре хезмәткәрләре оперативлык, материалны сыйфатлы итеп бәян итү, укучылар аудиториясе каршында җаваплылык хисе тоеп эшләүләре белән аерылып тора. Газеталар редакцияләре социаль-икътисадый һәм сәяси вакыйгаларны объектив яктыртырга, укучыларга социаль яктан әһәмиятле мәгълүмат җиткерергә, тормышның барлык якларын яктыртканда чама хисен саклап калырга тырыша. Бу иҗтимагый фикер тудыруга, Татарстан Республикасында халыкларның бергәләп яшәүләренең тыныч һәм дустанә мохитен барлыкка китерүгә ярдәм итә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, «Ватаным Татарстан» газетасы әдәби татар телен һәм татар мәдәниятен саклап калу һәм үстерү функциясен дә башкара, татар теле һәм татар халкы язмышына битараф булмаган милли зыялылар өчен үзенчәлекле рупор булып та тора.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан расланган дәүләт заданиеләре нигезендә редакцияләр Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый актларын бастырып чыгара. А2 форматында чыга торган «Республика Татарстан» газетасының тиражы 2016 елның беренче яртыеллыгында – 6180 нөсхә, икенче яртыеллыкта – 6015 нөсхә, шул ук форматтагы «Ватаным Татарстан» газетасы тиражы 4973 һәм 4437 нөсхә тәшкил итте.

Дәүләт заданиесен үтәү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирелә, газеталар редакцияләре шулай ук бюджеттан тыш чыганаклардан да керем ала. «Республика Татарстан» газетасы редакциясенең бюджеттан тыш керемнәре соңгы биш елда бюджеттан бүлеп бирелә торган акчалардан артыграк. «Республика Татарстан» газетасы редакциясенең штаттагы хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы республика буенча уртача айлык хезмәт хакыннан зуррак, «Ватаным Татарстан» газетасында – түбәнрәк.

Соңгы елларда газеталарның тиражлары кимү күзәтелә. Бу, беренче чиратта, басма матбугат чараларына җитди конкурент булган Интернет челтәре, электрон ММЧ һәм социаль челтәрләр үсешенә бәйле. Ике редакциянең дә электрон версияләре бар, бер айга «Ватаным Татарстан» газетасын – 20 мең, «Республика Татарстан» газетасын 120 мең кеше караган. Шул уңайдан газеталарның электрон версияләрен камилләштерү һәм аларны карау мәсьәләләре, эшнең яңа форматын табу, басма матбугатның тиражын саклап калу һәм үстерү өчен җитди чаралар күрү кирәклеге аеруча актуаль булып тора.



Вакытлы басма матбугатка язылу бәясен билгеләү, аны илтү һәм тарату хезмәтләренең почта аша сыйфатлы һәм үз вакытында күрсәтелүе проблемалары шактый киеренке булып кала. Бу исә халык арасында язылу кампанияләрен үткәрү динамикасына һәм газеталар тиражларына тискәре йогынты ясый.

Гасыр дәвамында басылып чыккан һәм республика тарихының документаль мирасының мөһим өлеше буларак архив фондларында тупланып барган газеталарны саклау мәсьәләсе хәл ителмәгән рәвешендә кала бирә. Газеталарны токсик һәм тиз бетә торган типография буявын кулланылган түбән сыйфатлы кәгазьдә бастыру технологияләренең үзенчәлекләренә бәйле рәвештә алар тиз таушала, шулай ук архив нөсхәләренең тулысынча юкка чыгу куркынычы да бар. Бу исә газета архивларын тиз арада цифрлаштыруны таләп итә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләренең эшчәнлеген камилләштерү һәм эш нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре эшчәнлеге турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Тәкъдим итәргә:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» республика газеталарының 100 еллык юбилейларына багышланган юбилей чараларын 2017 һәм 2018 елларда финанслау мөмкинлеген карарга.

2) Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан почтасы» федераль почта хезмәте идарәсе белән берлектә вакытлы басма матбугатка

язылу, илтү һәм дистрибуция (ваклап сату челтәре аша тарату) хезмәт күрсәтүләрен камилләштерү буенча чаралар күрергә.

3) Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары данәләре исәбен муниципаль китапханәләр өчен үзәкләштерелгән язылу кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән арттыру мөмкинлеген карарга.

4) «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына газеталар редакцияләренә хезмәткәрләрнең һөнәри квалификациясен күтәрү, аеруча аларның интернет кырында эшләүнең заманча алымнарын үзләштерүе өлешендә ярдәм күрсәтергә.

5) Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетына «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары архивларын берничә баскычтан гыйбарәт цифрлаштыру планын төзергә һәм аны тормышка ашыра башларга.

6) «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләренә:

басма матбугатларның тиражларын арттыру, укучылар аудиториясен киңәйтү максатларында яңа эшчәнлек форматларын кертү эшен активлаштырырга;

газета мәкаләләрендәге аналитиканы көчәйтергә, проблемалы мәсьәләләргә багышланган материаллар санын арттырырга;

газета битләрендә күтәрелә торган проблемаларны бергә хәл итү, закон чыгару эшен яктыртуны киңәйтү, депутатларның Татарстан Республикасы закон проектлары, законнары буенча комментарий бирүчеләр буларак катнашуын активлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары белән тагын да тыгызрак элемтәләр урнаштырырга;

редакцияләр тарафыннан укучылар аудиториясе белән оештырыла торган «туры элемтәләр»дә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкилләре белән беррәттән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләренә даими катнашуны тәкъдим итәргә;

газета контентын таратуның заманча каналларын куллануны, шул исәптән онлайн-версия хисабына, тәэмин итәргә;

2017 ел дәвамында газета сайтларының тәүлек буе яңартылып торуы мәсьәләсен хәл итәргә;

басма һәм электрон версияләрнең укучылар, файдаланучылар белән аралашуның адреслы формаларын кулланып, сайтта форумнар, сораштырулар, тавыш бирүләр оештырып, блогларда, социаль челтәрләрдә, төрле платформалар өчен мобиль кушымталар белән эшләп, аудитория белән хезмәттәшлек итүнең яңа баскычына күчүне тәэмин итәргә;

редакция икътисадын хәзерге чынбарлыкны исәпкә алып камилләштерергә, редакциянең керем базасын арттыру өчен хуҗалык эшчәнлеген диверсификацияләргә.



3. Гамәлгә куючылар советларына мөһим мәсьәләләрне үз вакытында тикшерүне тәэмин итәргә һәм, кирәк булган очракта, гамәлгә куючылар каравына «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына Татарстан Республикасында массакүләм мәгълүмат чараларын үстерү мониторингы буенча эшне дәвам итәргә һәм 2018 елның I кварталында үз утырышында әлеге карарның үтәлеше турында чыгышлар тыңларга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратниковага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 27 гыйнвары
№ 1596-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1271. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме бишенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме бишенче утырышын 2017 елның 16 февралендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 феврале
№ 1597-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1272. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме бишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме бишенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында.

3. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының 2016 елда полиция эшчәнлеге турында хисабы.

4. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 42 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 303-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 311-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

6. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 312-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 320-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 314-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 317-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» 302-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 307-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 295-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 297-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. Законнар һәм хокук куллану практикасы мониторингы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе турында.

15. «2016 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.

16. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.

17. Телерадиотапшырулар буенча Федераль конкурс комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында.

18. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 60768-7 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль берәмлек башлыгының отставкага китү нигезләмәсен төгәлләштерү өлешендә).

19. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 27 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 58281-7 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнарны ихтыярый салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

20. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 66082-7 номерлы федераль закон проекты хакында (стратегик планлаштыру өлкәсендәге мәсьәләләрне хокукый җайга салуның бердәм тәртибен билгеләү өлешендә).

21. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ростов өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

22. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 46193-7 номерлы федераль закон проекты хакында (балигъ булмаганнар турында мәгълүмат җыю һәм тарату тәртибен билгеләү өлешендә).

23. «Тирә-юньдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту зыяннарыннан гражданнар сәламәтлеген саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 42928-7 номерлы федераль закон проекты турында (электрон пар чыгаргычлардан тирә-юньгә таралган төтен йогынтысыннан һәм электрон пар чыгаргычлар өчен катнашмалар куллану зыяннарыннан гражданнар сәламәтлеген саклау өлешендә).



24. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына диңгез һәм эчке су транспортында хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуга кагылышлы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 52629-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

25. «Дарулар әйләнеше турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

26. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Федераль законның 18 статьясына үзгәреш кертү хакында» 25672-7 номерлы федераль закон проекты турында (эчәргә яраклы су, хуҗалык-көнкүрештә куллана торган су белән тәэмин итү өчен һәм дәвалау максатларында кулланыла торган су объектларын саклау округлары һәм санитария зоналары проектлары хакында).

27. «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 59961-7 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясендә Төньякның, Себернең һәм Ерак Көнчыгышның аз санлы төп халыкларына һәм аларның общиналарына шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү өлешендә).

28. «Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясына үзгәреш кертү турында» 60132-7 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен тартып алу нигезләрен киңәйтү өлешендә).

29. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 һәм 39.7 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 64793-7 номерлы федераль закон проекты хакында (җир кишәрлекләрен торглар уздырмыйча арендага бирү нигезләрен киңәйтү өлешендә).

30. «Россия Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминияте турында» Федераль законның 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 68586-7 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият кертеме тарифының мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен 8 % күләмендә гамәлдә булуын 2023 елга кадәр, шул елны да кертеп, озайту хакында).

31. «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 43719-7 номерлы федераль закон проекты турында (җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләренең Россия Федерациясе субъекты дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны били алуы хакында).

32. «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм коткаручыларның статусы турында» Федераль законга тау эшләре алып бару объектларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 60052-7 номерлы федераль закон проекты турында (тау эшләре алып бару объектларында һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү хакында).

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү турында» 61528-7 номерлы федераль закон проекты хакында (әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен вандализмнан яклау өлешендә).

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына транспорт чарасын хәвеф-хәтәр китереп чыгарырлык итеп йөрткән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 37057-7 номерлы федераль закон проекты турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 феврале
№ 1598-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1273. 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планын расларга (оригиналга кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 феврале
№ 1600-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1274. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, хисап бирү хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә (оригиналга кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 феврале
№ 1601-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1275. Ю.З. Камалтыновны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Россия дәүләтчелеген ныгытуга, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалы, парламентаризм, хәбәрдарлык һәм граждан җәмгыяте үсешенә лаеклы өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе

урынбасары Камалтынов Юрий Зимелевичны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләүгә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 феврале
№ 1602-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1276. Р.С. Хәкимовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Хәкимов Рафаил Сибгат улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 феврале
№ 1603-V ДС



# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1277. Е.А. Минакованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Фундаменталь медицина һәм биология институтының биоэкология, гигиена һәм җәмәгать сәламәтлеге кафедрасы доценты Минакова Елена Анатольевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 9 гыйнвары
№ 1-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1278. Ә.Б. Сафинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен эчке хезмәт майоры, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат һәм иҗтимагый элемтәләр бүлеге өлкән референты Сафина Әлфия Бәһрам кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 10 гыйнвары
№ 2-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1279. Ә.Ф. Әхмәдиевне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Бөгелмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге Бөгелмә җирле бүлекчәсенең җирле башкарма комитеты җитәкчесе Әхмәдиев Әнвәр Фатыйх улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 11 гыйнвары
№ 3-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1280. Т.Т. Җәләлетдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге Арча җирле бүлекчәсенең җирле башкарма комитеты җитәкчесе Җәләлетдинов Тәлгать Таһир улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 11 гыйнвары
№ 4-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1281. Р.Р. Мөхәммәтгалиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Әтнә муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге Әтнә җирле бүлекчәсенең җирле башкарма комитеты җитәкчесе Мөхәммәтгалиева Равилә Рәкыйп кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 11 гыйнвары
№ 5-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1282. Е.Н. Ефременкованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге Лениногорск җирле бүлекчәсенең җирле башкарма комитеты җитәкчесе Ефременкова Елена Николаевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 11 гыйнвары
№ 6-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1283. Ю.С. Решетовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен юридик фәннәр докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты юридик факультетының дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы кафедрасы профессоры Решетов Юрий Сергеевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 12 гыйнвары
№ 7-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1284. Р.Р. Саттаровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен полиция капитаны, «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең иң югары вазыйфаи затларның иминлеген тәэмин итү үзәгенең беренче бүлегендәге 3 нче бүлекчә инспекторы Саттаров Руслан Ринат улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 16 гыйнвары
№ 8-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1285. Д.Ю. Бобковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен полиция капитаны, «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең иң югары вазыйфаи затларның иминлеген тәэмин итү үзәгенең беренче бүлегендәге (иминлекне тәэмин итү) 3 нче бүлекчә инспекторы Бобков Дмитрий Юрьевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 16 гыйнвары
№ 9-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1286. А.А. Макуринны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен полиция майоры, «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең югары вазыйфаи затлар иминлеген тәэмин итү үзәгенең мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүмати яклау бүлегенең 1 нче номерлы бүлекчәсе баш белгече Макурин Александр Александровичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 16 гыйнвары
№ 10-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1287. Ю.А. Кравченконы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Казан төгәл машиналар төзү заводы» федераль казна предприятиесенең компрессор җитештерүдә компрессор җайланмалар әзерләү цехы башлыгы Кравченко Юрий Анатольевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 19 гыйнвары
№ 12-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1288. М.Л. Малышевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе суд приставларының Азнакай район бүлеге башлыгы – өлкән суд приставы Малышев Максим Леонидовичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 20 гыйнвары
№ 13-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1289. «Miras» уен кораллары ансамбле коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Miras» уен кораллары ансамбле коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 20 гыйнвары
№ 14-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1290. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 311-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмле-

генең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 311-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 16 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 20 гыйнвары
№ 15-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1291. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 312-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын («Болгар шәһәре», «Приволжский авыл җирлеге» һәм «Өчкүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:



1. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 312-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 17 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 20 гыйнвары
№ 16-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1292. А.Х. Фәссаховны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге иҗтимагый советы әгъзасы Фәссахов Анур Хөснетдин улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 20 гыйнвары
№ 17-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1293. З.А. Муравьеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарәсен үстерүгә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртово авыл җирлегенең башкарма комитеты секретаре Зоя Алексеевна Муравьеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 23 гыйнвары
№ 18-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1294. М.Х. Кәбировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге башлыгы Кәбиров Мирзанур Хаҗи улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 23 гыйнвары
№ 19-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1295. Е.Е. Гущинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча баш медицина-социаль экспертизасы бюросы» федераль казна учреждениесенең юридик бүлеге башлыгы Гущина Екатерина Евгеньевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 23 гыйнвары
№ 20-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1296. А.Н. Гайфуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча баш медицина-социаль экспертизасы бюросы» федераль казна учреждениесенең 3 нче эксперт советы җитәкчесе – медицина-социаль экспертиза буенча табибы Гайфуллин Айрат Нурислам улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 23 гыйнвары
№ 21-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1297. Р.Р. Камалиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Буа районара тикшерү бүлеге җитәкчесенең өлкән ярдәмчесе Камалиев Риаз Риза улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 24 гыйнвары
№ 22-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1298. М.Л. Галиевне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Әлмәт шәһәре буенча тикшерү бүлеге җитәкчесенең өлкән ярдәмчесе Галиев Марат Ләис улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 24 гыйнвары
№ 23-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1299. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Н.Ө. Мәганов тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 313-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (2013 елның 1 гыйнварыннан исәпкә алынган күчемле мөлкәтне салым салудан азат итү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 313-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә алу өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Күрсәтелгән закон проектын Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясындагы өченче өлеше нигезендә бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 23 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 25 гыйнвары
№ 24-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1300. Ф.Б. Гайнемөхәммәтовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Түбән Кама муниципаль районының «Сандугачлар оясы» халык гаилә ансамбле коллективы җитәкчесе Гайнемөхәммәтов Флер Бикмөхәммәт улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 25 гыйнвары
№ 26-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1301. Л.Ә. Миңнуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Бөгелмә муниципаль районының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы Миңнуллина Лена Әмир кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 25 гыйнвары
№ 27-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1302. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 314-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата киметелгән салым ставкаларын билгеләү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 314-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә алу өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 24 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 26 гыйнвары
№ 28-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1303. А.Ю. Кудрявцевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы бүлеге полиция башлыгы урынбасары Кудрявцев Александр Юрьевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 26 гыйнвары
№ 29-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1304. И.М. Фәссахетдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча ветераны Фәссахетдинов Илнур Мөфтахетдин улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 26 гыйнвары
№ 30-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1305. Ф.Б. Баһаветдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Озак еллар фидакарь хезмәт иткән һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген техник тәэмин итүгә үзеннән зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген мәгълүмати-техник тәэмин итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече Баһаветдинов Фәсхетдин Борис улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 30 гыйнвары
№ 31-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1306. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Т. Борһанов, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 315-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (терминологияне федераль законнарга туры китерү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының

кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 315-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 30 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 1 феврале
№ 32-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1307. Р.Х. Мусинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Аксубай муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Аксубай муниципаль районының «Аксу Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сөттовар комплексы идарәчесе Мусин Равил Хәйдәр улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2017 елның 2 феврале
№ 33-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 1308. А.Г. Золинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

